КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 апрель г.Казань № 236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 апрель, 167 нче; 2007 ел, 5 октябрь, 533 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 март, 171 нче; 2008 ел, 25 июнь, 429 нчы; 2009 ел, 27 март, 179 нчы; 2010 ел, 1 февраль, 49 нчы; 2012 ел, 15 май, 376 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 август, 620 нче; 2014 ел, 21 май, 338 нче; 2017 ел, 24 март, 179 нчы, 2017 ел, 01 ноябрь, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүне сорап мөрәҗәгать итү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән компенсация билгеләнгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;

мөрәҗәгать итүченең гаилә составында әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә исәпкә алынган бала туу турында таныклык күчермәсен, аңа элегрәк чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән компенсация һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен билгеләнә;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән баланы уллыкка алу турында таныклык күчермәсен;»;

җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

8.1 пунктының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«компенсация билгеләнә торган баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең гаилә составында исәпкә алынган баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр, моңа кадәр компенсация билгеләнә торган бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче; 2015 ел, 29 июль, 550 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 997 нче; 2017 ел, 13 июль, 494 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 839 нчы; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;»;

8 пунктның икенче абзацында «граждан хәле актларын теркәү органы» сүзләрен «Федераль салым хезмәте» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 июнь, 507 нче; 2019 ел, 22 август, 698 нче; 2020 ел, 26 февраль, 148 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ана үлеме турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;»;

7 пунктта:

икенче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә үлем актын дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 27 декабрь, 1207 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ана үлеме турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен;»;

6 пунктта:

икенче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин